ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«12» 11 2020г.** **№874**

"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең 2021 елга балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль -педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

Россия Федерациясе «Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге «Балаларга өстәмә белем бирү туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләре һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» №939 карары нигезендә һәм “Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга расларга:

"Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирү буенча туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы күппрофильле белем бирү оешмаларында белем бирү программаларын тормышка ашыруга кушымта итеп бирелгән норматив чыгымнарны расларга;

балаларга өстәмә белем бирү буенча туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем

бирү программаларын тормышка ашыручы күппрофильле белем бирү оешмалары программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмә коэффициентын 0,5 күләмендә билгеләргә.

2. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булган чоры дәвамында балаларга өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган хезмәт хакын индексацияләү белән, яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

А. В. Сучкова

2-80-12

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
расланды

«____» __________20__№____

«Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Урнашкан урыны | Бер укучыга елга норматив чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Белем алуның беренче елы | Белем алуның икенче елы | Белем алуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгать-эстетик | Шәһәр җире | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | Авыл җире | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | Шәһәр җире | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | Авыл җире | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | Шәһәр җире | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | Авыл җире | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык – төбәкне өйрәнү | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | Авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | Авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | Авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | Шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | Авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисад | Шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | Авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | Шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | Авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |